Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Олы Талкыш авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре №7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Каратаевка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 12.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Каратаевка авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Каратаевка авылы, Кыр ур., 25 нчы йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Каратаевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 200 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- зират территориясен төзекләндерү (коймалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ЯКЛЫ» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Олы Талкыш
авыл җирлеге башлыгы Э.Б.Ильин